**Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Яке авыл җирлеге муниципаль берәмлеге гражданнар җыены карары (КАРАР)**

«13» ноябрь 2019 ел № 1

**Мамадыш муниципаль районы**
**Яке авыл җирлеге составына керүче**
**Дегетле авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә принциплары турында»гы 6 октябрь, 2003 ел, 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 нче маддәләре, "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында"гы 28 июль, 2004 ел, 45-ЗРТ санлы Татарстан Республикасы законының 35 нче маддәсе, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Яке авыл җирлеге муниципаль берәмлеге» Уставының 23 ст., Мамадыш муниципаль районы Яке авыл җирлегенең Дегетле авылында 2019 елның 13 нче ноябрндә узган үзара салым акчаларын куллану һәм кертү буенча түбәндәге сорау буенча гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә:

"Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Яке авыл җирлегенең Дегетле торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга, 1 һәм 2 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашкан ветераннар, Бөек Ватан сугышында һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашканнарның тол хатыннары, күп балалы гаиләләр, көндезге бүлектә белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән кала, 2020 елда 400 сум күләмендә үзара салым кертелүгә һәм ул акчаларны түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен тотылуына сез ризамы:

- Дегетле авылында, Комлык урамына вак таш җәю ( сатып алу, ташу, вак таш җәю, килешү буенча түләү).
-Дегетле торак пунктындагы юлларны тигезләү һәм кардан чистарту.

« ӘЙЕ» «ЮК».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 60 кеше кертелгән;
халык җыенында тавыш бирүдә катнашучылар саны: 42 кеше;
Халык җыенында катнашучыларның ачык тавыш бирү нәтиҗәләре түбәндәгечә бүленде:
«Әйе» 42 кеше тавыш бирде;